**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XIII УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 22**

Шуган ав. 09 июнь 2021 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 08 ноябрендәге 1 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлеге Советы карарына үзгәреш кертү хакында**

Гамәлдәге законга туры китерү максатында, Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 08 ноябрендәге 1 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

- 116.13 пунктны «(әмма тиешле тәртиптә төзелгән һәм дәүләт кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләренең милекчеләре өчен, әгәр Россия Федерациясе законнарында каралган мәҗбүри таләпләрне бозмаса, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында Карар кабул итү мөмкинлеге тулысынча юкка чыгарылырга тиеш түгел)» дигән җөмлә белән тулыландырырга.

2. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 13 ноябрендәге 47 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлеге Советы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Шуган авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Шуган авыл җирлеге башлыгы** **Басорина А.Ю.**